**Татарстан Республикасы Азнакай район Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре №301-41 «12» декабрь 2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы муниципаль милеген 2020 елга хосусыйлаштыруның фараз планын раслау турында

2001 елның 21 декабрендәге «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» № 178-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2018 елның 12 ноябрендәге 210-31нче номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында»гы Нигезләмә белән

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы муниципаль милеген 2020 елга хосусыйлаштыруның фараз планын, 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы» муниципаль казна учреждениесенә (рәисе Хәйдәров И.З.) Азнакай муниципаль районының 2020 елга муниципаль милкен хосусыйлаштыруның фараз планын гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Россия Федерациясенең рәсми сайтында, сатуларны үткәрү турында Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән мәгълүматны урнаштыру өчен, түбәндәге веб-адрес буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыырга: http://aznakayevo.tatar.ru, рәсми басма - «Татмедиа» филиалының «Маяк» район газетасында бастырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З.Шәйдуллин

Татарстан Республикасы Азнакай район
Советы карарына кушымта
«12» декабрь 2019 №301-41

2020 елга Азнакай муниципаль районының муниципаль милекне хосусыйлаштыруның фаразланган планы

1. Азнакай муниципаль районының 2020 елга муниципаль милекне хосусыйлаштыруның фаразлау планы (алга таба - фараз планы) 2001елның 21 декабрендәге «Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 178-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль Советының 2018 елның 12 декабрендәге 210-31 номерлы карары белән расланган, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында» нигезләмә нигезендә эшләнде һәм Азнакай муниципаль районында муниципаль милекне хосусыйлаштыру мәсьәләләрен, чикләүләрне һәм үзенчәлекләрен билгели.

2. 2020 елда Азнакай муниципаль районына муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру муниципаль милеккә идарә итүнең нәтиҗәлелеген күтәрүгә, күчемсез милек объектларын тотуга инвестицияләр җәлеп итүгә, муниципаль мөлкәтне сатудан керемнәр белән район бюджеты кытлыгын каплау чыганакларын булдыруга юнәлдерелгән.

3. 2001 елның 21 декабрендәге «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруны Азнакай муниципаль районының муниципаль милкендәге күчемсез милек һәм күчемле мөлкәт объектларын аукционда яисә конкурста законда каралган башка ысуллар белән сату юлы белән башкару күздә тотыла.

4. 2020 елда муниципаль казнадагы түбәндәге муниципаль мөлкәт хосусыйлаштырылырга тиеш:

| п/п | Исеме һәм төп характеристикалары | Адресы | Сатуларны үткәрү вакыты |
|---|---|---|---|
| 1 | Җир кишәрлеге белән торак булмаган гараж бинасы | Татарстан Республикасы, Азнакай шәһәре, Николаев ур., 5В | 1 нче яртыеелык |
| 2 | Җир кишәрлеге белән торак булмаган гараж бинасы | Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Әсәй авыл җирлеге, Әсәй авылы (элекке балалар бакчасы) | 1 нче яртыеллык |
| 3 | Җир кишәрлеге белән торак булмаган гараж бинасы | Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Әсәй авыл | 1 полугодие |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | җирлеге, Метрәй авылы<br>(элекке фельдшер-акушерлык пункты) | |
| 4 | Җир кишәрлеге белән торак булмаган гараж бинасы | Татарстан Республикасы,<br>Азнакай муниципаль районы, Микулино авыл җирлеге,<br>Микулино авылы<br>(элекке фельдшер-акушерлык пункты) | 1 яртыеллык |

5. Фараз планына кергән муниципаль милекне хосусыйлаштыру шартлары турында карарлар кабул итү, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы» тарафыннан 2001 елның 21 декаберендәге «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Азнакай муниципаль районының муниципаль милкен хосусыйлаштыру комиссиясе тәкъдимнәре нигезендә гамәлгә ашырыла.

6. Фараз планына кермәгән муниципаль милекне хосусыйлаштыру шартлары турында карарлар кабул итү, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы» тарафыннан 2001 елның 21 декаберендәге «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Азнакай муниципаль районының муниципаль милкен хосусыйлаштыру комиссиясе тәкъдимнәре нигезендә гамәлгә ашырыла.

7. Азнакай муниципаль районы муниципаль милкен хосусыйлаштыруны оештыруга һәм үткәрүгә акча түбәндәге чыгымнар төрләре буенча сарыф ителә дип билгеләргә:

- мөлкәтне сатуга әзерләү, шул исәптән техник һәм кадастр документларын рәсмиләштерү;
- базар бәясен билгеләү һәм башлангыч бәя билгеләү өчен мөлкәтне бәяләү;
- сатып алучылар тарафыннан үз йөкләмәләренең үтәлешен исәпкә алу һәм контрольдә тоту буенча эшчәнлекне тормышка ашыру;
- Азнакай муниципаль районының судларда милек һәм башка хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау;
- мәгълүмати-коммуникацион системалар булдыру һәм аларга хезмәт күрсәтү, мөлкәтне сатуның матди-техник базасын камилләштерү.